**СОВЕТ АЛЕКСАНДРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**422613 н.п. им. «25 Октября»**
**тел: 8-(84378) -3-54-22**
**факс: 8-(84378) -3-54-22**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛЕКСАНДР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**422613 н.п. им. «25 Октября»**
**тел: 8-(84378) -3-54-22**
**факс: 8-(84378) -3-54-22**

2024 елның 16 мае 26 номер

КАРАР

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2014елның 14 ноябрендәге 15 номерлы Александр авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 декабрендәге 15 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлеге советы карарына (15.05.2015 № 10, 12.10.2015 № 19, 17.10.2018 № 34, 02.11.2018 № 38/1, 07.10.2020 № 9, 25.11.2022 № 70 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 3 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацны:

"Салым ташламасына хокуклы затлар салым органына ташламалар бирү турында гариза, шулай ук салым ташламасына хокукны раслый торган документлар тапшыра."

яңа редакциядә бәян итәргә:

"Салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гаризаны үз сайлавы буенча тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документлар тапшырырга хокуклы."

1.2. 3 пунктта түбәндәге эчтәлекле 3.4 пунктча өстәргә:

«3.4. Салым ташламасына хокуклы салым түләүчеләр категорияләре Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясында билгеләнгән.»

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлеге Советы рәисе вазыйфаларын башкаручы** **Ю.Г.Трифонова**